**Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы**

**Иске Тимошкино авыл җирлеге составына керүче**

**Батыр авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

**КАРАР**

12.11. 2020 № 5

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131 - ФЗ Федераль закон 25.1, 56 статьясы нигезендә», «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы 35 статьясы, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы «Иске Тимошкино авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы 24 статьясы, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Тимошкино авыл җирлеге Советы «Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Тимошкино авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау турында» 05.11.2019 ел, №99 карары нигезендә, 2020 елның 12 ноябрендәге Иске Тимошкино авыл җирлегендә Батыр авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча гражданнар җыены беркетмәсе төзелде: «2021 елда үзара салым кертүгә Аксубай муниципаль районы Иске Тимошкино авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган һәр кешедән, I төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш, 300 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме:

1. Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

- авыл эчендәге юлларны ремонтлау (вак ташны (ЩПС) сатып алу, грунтны һәм вак ташны күтәрү, җәю һәм тигезләү (килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү).

2. Беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, янгын сүндерү машинасын йөртүчеләрнең хезмәт хакы)

«РИЗА» «КАРШЫ» «ТЫЕЛЫП КАЛДЫЛАР»

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә 17 граждан кертелгән. ____ гражданнар җыенында катнашучыларның саны.

Ачык тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Риза» позициясе өчен 17 граждан тавыш бирде;

«Каршы» позициясе өчен 0 граждан тавыш бирде;

«Тыелып калдылар» позициясе өчен 0 граждан тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Тимошкино авыл җирлегенең Батыр авылында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләре дөрес дип танырга.

Мәсьәлә буенча карар кабул итәргә: «2021 елда үзара салым кертүгә Аксубай муниципаль районы Иске Тимошкино авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган һәр кешедән, I төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш, 300 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме:

1. Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

- авыл эчендәге юлларны ремонтлау (вак ташны (ЩПС) сатып алу, грунтны һәм вак ташны күтәрү, җәю һәм тигезләү (килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү).

2. Беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, янгын сүндерү машинасын йөртүчеләрнең хезмәт хакы)

3. Иске Тимошкино авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында әлеге карарны игълан итәргә, Аксубай муниципаль районы рәсми сайтында урнаштырырга: http://aksubaevo.tatar.ru һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
ТР Аксубай муниципаль районы
Иске Тимошкино авыл җирлеге башлыгы П. А. Мулеева